ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2025 г.Казань № 704-215/кс-2025

Түбән Кама муниципаль районының «Нижнекамский Жилкомсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2026 елга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2025 ел, №35-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының «Нижнекамский Жилкомсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Нижнекамский Жилкомсервис» ҖЧҖ) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нижнекамский Жилкомсервис» ҖЧҖ иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат

ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 704-215/кс-2025
карарына кушымта

## Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нижнекамский Жилкомсервис» ҖЧҖ өчен 2026 елга кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | | | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Нижнекамский Жилкомсервис» ҖЧҖ* | | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)** | 216,55 | 203,92 | 231,71 | 218,57 | 256,67 | 241,83 | 274,47 | 259,04 |

* Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
** Россия Федерациясе Салым кодексының 164 статьясындагы 8 пунктының 1 пунктчасында билгеләнгән салым ставкасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге